# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **11.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Тойгелде авыл җирлеге составына керүче Ташлыяр торак пунктында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлегенә керүче Ташлыяр торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Ташлыяр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә; I, II төркем инвалидларга, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларга, армия хезмәте узучыларга; көндезге бүлектә белем алучы студентларга, 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Ташлыяр авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- Ташлыяр авылы мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял вакытын оештыру һәм халыкны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, Ташлыяр авылы җирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыруга;
- Ташлыяр авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыруга;
- Ташлыяр авылы җирлеген төзекләндерүне оештыруга;
- Ташлыяр авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыруга;
- Ташлыяр авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Ташлыяр авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Тойгелде авылы, Үзәк урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тойгелде авыл җирлеге башлыгы Минһаҗев Д.М.